КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 июль г.Казань № 551

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе структурасын, хезмәткәрләренең иң чик санын һәм хезмәт өчен түләү фондын раслау турында» 2013 ел, 26 декабрь, 1060 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе структурасын, хезмәткәрләренең иң чик санын һәм хезмәт өчен түләү фондын раслау турында» 2013 ел, 26 декабрь, 1060 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 декабрь, 965 нче; 2017 ел, 16 август, 588 нче; 2018 ел, 14 май, 365 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1303 нче; 2019 ел, 23 июль, 616 нчы; 2020 ел, 23 октябрь, 948 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1364 нче; 2022 ел, 10 октябрь, 1087 нче; 2023 ел, 3 февраль, 95 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды турында бертип нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 21 гыйнварындагы 15н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды турында бертип нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 3 октябрендәге 524н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик санын – 409 берәмлек, шул исәптән дирекциянекен – 208 берәмлек, филиалларныкын – 201 берәмлек итеп, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фондын – 9 017,403 мең сум күләмендә, шул исәптән дирекциянекен – 5 060,883 мең сум, филиалларныкын 3 956,52 мең сум күләмендә билгеләргә.».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин